СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ**
30 июль, 2026 ел

**КАРАР**
№ 86

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмә хакында» 2014 елның 08 декабрендәге 400 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмә хакында» 2014 елның 08 декабрендәге 400 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяда «бәйсезлек» сүзеннән соң «, ачыклык» сүзен өстәргә.

1.2. 5 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр Биектау муниципаль районы Советына түбәндәгеләр тарафыннан кертелә:

1) Биектау муниципаль районы Советы рәисе;

2) Биектау муниципаль районы Советы депутатлары тарафыннан - Биектау муниципаль районы Советы депутатларының билгеләнгән санынnan өчтән береннән ким түгел;

3) Биектау муниципаль районы Башлыгы.»

1.3. 5 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына тәкъдим ителгән кандидатураларны караганда, Биектау муниципаль районы Советы

кандидатураның квалификация таләпләренә туры килүе турында бәяләмә сорап Татарстан Республикасы Хисап палатасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»

1.4. 6 статьяның 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белеме булу;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эш тәҗрибәсе;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны, Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турында законнарын, Россия Федерациясенең тиешле субъекты Конституциясен (уставын), законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, тиешле муниципаль берәмлек Уставын һәм вазыйфаи бурычларны үтәүгә мөнәсәбәтле башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары тарафыннан контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына гомуми таләпләрне белүе.»

1.5. 6 статьяның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Контроль-хисап палатасы рәисе, аудиторлары вазыйфаларын биләүче гражданнар Биектау муниципаль районы Советы рәисе, Биектау муниципаль районы Башлыгы, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта яки якынлыкта була алмыйлар (ата-аналары, ире яки хатыны, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир белән хатынның абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары, балалары һәм балаларының ирләре, хатыннары)..»

1.6. 7 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны

тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәү.»

1.7. 8 статьяның 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка акчалардан файдалануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) Биектау муниципаль районы бюджеты проектларына экспертиза ясау, аның күрсәткечләренең нигезлелеген тикшерү һәм анализлау;

3) Биектау муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү;

5) муниципаль милек формалаштыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милек формалаштыруның, мондый милек белән идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибе үтәлешен контрольдә тоту (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә бердәнбер хокукларны да кертеп);

6) Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары һәм Биектау муниципаль районы милкендәге мөлкәт исәбеннән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләр буенча муниципаль гарантияләр һәм поручительлекләр бирүнең яисә йөкләмәләрнең башка ысуллар белән үтәлешен тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) Биектау муниципаль районының чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә муниципаль хокукый актлар проектларына экспертиза ясау, Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларына, шулай ук муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына) экспертиза ясау;

8) Биектау муниципаль районында бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) агымдагы финанс елында Биектау муниципаль районы бюджеты үтәлешенә оператив анализ һәм үтәлешен оештыруга тикшерү үткәрү, Биектау

муниципаль районы бюджеты үтәлеше барышы турында, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында квартал саен мәгълүматны Биектау муниципаль районы Советына һәм Биектау муниципаль районы Башлыгына тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурычның торышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

11) муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы компетенциясе чикләрендә Биектау муниципаль районының стратегик планлаштыру документларында каралган Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешү мөмкинлеген, куркынычларын һәм нәтиҗәләрен бәяләү;

12) коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләр чикләрендә катнашу;

13) тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендә федераль законнарда, Россия Федерациясе субъекты законнарында, Биектау муниципаль районы Уставында һәм Биектау муниципаль районы Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләр.»

1.8. 8 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда башка затларга карата.»

1.9. 17 статьяның 1 пунктында «аларны карау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «ачыкланган» сүзеннән соң «бюджет һәм башка»сүзләрен өстәргә.

1.10. 17 статьяның 3 пунктында «күрсәтмәне алган көннән алып бер ай эчендә» сүзләрен «күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта яисә, әгәр срок күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән алып 30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга, «карау» сүзен «үтәү» сүзенә алмаштырырга.

1.11. 17 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтмәне үтәү срогы контроль-хисап органы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.»

1.12. 17 статьяның 8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) Контроль-хисап палатасының тәкъдимен яисә күрсәтмәсен үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов